**СОВЕТ КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

**2022 елның« 14 » ноябре** **11 номер**

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында” 2022 елның 19 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү**

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә Хәерби авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында” 2022 елның 19 октябрендәге 7 номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 маендагы 88 номерлы «Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары белән расланган Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларына карап, 2022 елның 1 октябреннән күтәрергә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Хәерби авыл җирлеге**
**Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы Р.К.Зиннәтуллин**